**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.01.2019 Казан шәһәре № 4

«Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында коррупция куркынычлары булган эшкә билгеләнгәндә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле Татарстан Республикасы Дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында»

2008 елның 25 декабрендә кабул ителгән 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законын, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендә кул куелган УП-701 номерлы «Эшкә билгеләнгәндә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле Татарстан Республикасы Дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында»

Указын, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендә кул куелган УП-702 номерлы «Эшкә билгеләнүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында» Указын, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 30 сентябрендә кул куелган «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру буенча чаралар турында» УП-636 номерлы Указын, шулай ук Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 22 июнендә кул куелган УП-454 номерлы «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгын үзгәртеп кору турында» Указын үтәү йөзеннән, **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында (алга таба – Министрлык) коррупция куркынычлары булган эшкә билгеләнгәндә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле Татарстан Республикасы Дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларының теркәлә торган исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча секторга:

Исемлеккә кертелгән вазыйфаларга билгеләнә торган дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә аларны эштән азат иткән вакытта 2008 елның 25 декабрендә кабул ителгән 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законының 12 маддәсендә каралган чикләүләр, бурычлар һәм җаваплылыкны аңлатырга;

әлеге боерыкны Министрлыкның Исемлеккә кертелгән дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә җиткерергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үз өстемдә калдырам.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
2019 елның 15гыйнварендә кул куелган
4 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында коррупция куркынычлары булган эшкә билгеләнгәндә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле
Татарстан Республикасы Дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеге

| №№ | Вазыйфа атамасы | Вазыйфалар саны |
|---|---|---|
| 1 | Министрның беренче урынбасары | 1 |
| 2 | Министр урынбасары | 2 |
| 3 | Бүлек башлыгы – үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчесе | 1 |
| 4 | Министр ярдәмчесе | 1 |
| | Юридик һәм мобилизацияләү эше секторы | |
| 1 | Сектор мөдире | 1 |
| | Дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча сектор | |
| 1 | Сектор мөдире | 1 |
| | Фаразлау, бюджет планлаштыру бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы белгеч | 3 |
| | Спорт инфраструктурасын үстерү һәм программаларны тормышка ашыру бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы киңәшче | 3 |
| 3 | Әйдәп баручы консультант | 1 |
| | Матди-техник тәэминат һәм дәүләт заказы бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы белгеч | 2 |
| | Халыкара эшчәнлек, аналитика һәм мәгълүмат белән тәэмин итү бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| | Югары казанышлар спортын үстерү бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы белгеч | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| Спорт резервын әзерләү секторы | | |
| 1 | Сектор мөдире | 1 |
| Массакүләм физкультура-сәламәтләндерү эше бүлеге | | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы чараларын тормышка ашыру буенча сектор | | |
| 1 | Сектор мөдире | 1 |
| Адаптив физкультура һәм студентлар спорты секторы | | |
| 1 | Сектор мөдире | 1 |
| Эшләр белән идарә итүче | | |
| 1 | Эшләр белән идарә итүче | 1 |
| Оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлеге | | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| Гомуми мәсьәләләрне оештыру буенча сектор | | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы белгеч | 1 |
| БАРЛЫГЫ: | | 31 |